ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 3-05-44, факс: (84379) 3-05-44.

05.12.2024 ел № №3

На № ________ от ________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендәге гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 12 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:-Түбән Ослан торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча 2024 елның "05" декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда катнашучы 13 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучы гражданнар саны - 2 кеше. Кворум юк. Гражданнарның җыены көн тәртибенә кагылышлы карарлар кабул итәргә тиеш түгел.

Карар кабул ителде:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены булмаган дип санарга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгына җибәрергә.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев